# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ РАЙОН СОВЕТЫ

(V чакырылыш)

V чакырылышның чираттан тыш утырышы

## КАРАРЫ

«30» декабрь 2025 ел № 32 Урыссу ш.т.б.

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының җирле үзидарә органнарында һәм муниципаль бюджет учреждениеләрендә бюджет (бухгалтерлык) исәбен һәм хисаплылыгын үзәкләштерү турында

"Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ санлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәнең гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль закон, "Бухгалтерлык исәбе турында"гы 06.12.2011 № 402-ФЗ Федераль законы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 28.07.2004 ел, № 45-ТРЗ Татарстан Республикасы законы нигезендә, "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы" муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының җирле үзидарә органнарында һәм муниципаль бюджет учреждениеләрендә бюджет (бухгалтерлык) исәбен һәм хисаплылыгын үзәкләштерү максатларында, Татарстан Республикасы Ютазы район Советы карар кабул итте:

1. 2026 елның 1 февраленнән Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының җирле үзидарә органнарында һәм муниципаль бюджет учреждениеләрендә бюджет (бухгалтерлык) исәбен һәм хисаплылыгын алып бару вәкаләтләрен Ютазы муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына бирергә.

2. Ютазы муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы рәисе Мөхәмmәтова Руфия Габделмәҗит кызына 2026 елның 1 февраленә кадәр:

- Ютазы муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына бирелгән вәкаләтләрнең һәм функцияләрнең үтәлешен тәэмин итәргә һәм, Россия Федерациясенең гамәлдәге законнары таләпләре нигезендә, әлеге карарны гамәлгә ашыру максатларында оештыру-штат чараларын гамәлгә ашырырга;

- Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының хезмәт күрсәтелә торган җирле үзидарә органнары һәм муниципаль бюджет учреждениеләре җитәкчеләре белән тиешле шартнамә төзеп, әлеге карар нигезендә бюджет (бухгалтерлык) исәбен алып баруны оештырырга;

- Ютазы муниципаль районы Финанс-бюджет палатасының иң чик штат саныннан чыгып, Ютазы муниципаль районы Финанс-бюджет палатасының структурасын һәм штат расписаниесен эшләргә һәм расларга - 46 ставка;

- Ютазы муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы белән хезмәт күрсәтелә торган җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының муниципаль бюджет учреждениеләре арасында документлар әйләнеше тәртибен эшләргә һәм расларга.

3. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының җирле үзидарә органнары һәм муниципаль бюджет учреждениеләре җитәкчеләренә бюджет (бухгалтерлык) исәбен һәм хисаплылыгын алып бару максатларында әлеге карарга таянырга.

4. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының бердәм порталы «Рәсми Татарстан» Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://jutaza.tatarstan.ru/.

5. Әлеге карар кабул ителгән көннән үз көченә керә.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Ютазы район Советының Бюджет, салымнар, инвестицияләр һәм эшкуарлык буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль
районы Башлыгы,
Татарстан Республикасы
Ютазы район Советы Рәисе А.Ә. Шәфигуллин

Р.М. Якупов
(8-85593) 2-42-05